| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

07 ноябрь 2025 ел — № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Сарайлы авылы өлешендә 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Сарайлы авылы, М.Җәлил урамы, 39 а йорты адресы буенча урнашкан Мәдәният йорты бинасында 2025 нче елның 21 ноябренә 11 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Сарайлы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан кала, Сарайлы авылы Ләшәү Тамак авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Сарайлы авылы, Космонавтлар урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);

2) Сарайлы авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

3) Сарайлы авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);

4) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

«ӘЙЕ» — «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Ләшәү Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы: И.З.Хабибуллин